**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «03» апреленнән № 95

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендә мини-фермалар төзү өчен агач (урман) материаллары, цемент һәм керамзит блоклар (төзелеш материаллары) сатып алуга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 9 февралендәге 54 номерлы карарына (2022 елның 26 маендагы 158 номерлы, 2022 елның 20 сентябрендәге 265 номерлы карарлардагы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендә мини-фермалар төзү өчен агач (урман) материаллары, цемент һәм керамзит блоклар (төзелеш материаллары) сатып алуга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 9 февралендәге 54 номерлы карарына (2022 елның 26 маендагы 158 номерлы, 2022 елның 20 сентябрендәге 265 номерлы карарлардагы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга сөтчелек юнәлешендә мини-фермалар төзүгә агач (урман) материаллар, цемент һәм керамзит блоклар (төзелеш материаллары) сатып алуга субсидияләр бирү тәртибендә:

5нче пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) «Интернет» мәгълүмат–

телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталындагы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru гаризалар сайлап алуны үткәрү турында мәгълүмат (алга таба - сайлап алуны үткәрү турында игълан) урнаштыра:»;

өченче абзацта «30-нан алданрак » сүзләрен «10-нан алданрак» сүзләренә алмаштырырга.

10 пунктның 13 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан расланган сөт юнәлешендәге мини-ферма төзелешенә стеналар төзү өчен агач (урман) материаллары, цемент һәм керамзит блоклар (төзелеш материаллары) яки башка төзелеш материаллары сатып алу белән бәйле чараларны гамәлгә ашыру максатларында шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар белән ике яклы килешү төзи;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http// novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Р. Фасахов